# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Оешмалар мөлкәтенә салым турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм оешмалар мөлкәтенә салым турында Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"ОЕШМАЛАР МӨЛКӘТЕНӘ САЛЫМ ТУРЫНДА"**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ**

Әлеге Закон белән Татарстан Республикасы территориясендә оешмалар мөлкәтенә салым (алга таба – салым) кертелә.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Салым Россия Федерациясе Салым кодексы һәм әлеге Закон белән билгеләнә.
2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым ставкасын, аны түләү тәртибен һәм вакытларын, шулай ук салым ташламаларын һәм аларның салым түләүчеләр тарафыннан кулланылу нигезләрен билгели.

2 статья. **Салым ставкасы**

Салым ставкасы 2,2 процент күләмендә билгеләнә.

3 статья. **Салым ташламалары**

1. Салым салудан түбәндәгеләр мөлкәте азат ителә:

1) Татарстан Республикасы Алабуга районында урнашкан "Алабуга" Алабуга автомобиль заводы сәнәгать мәйданчыгы территориясендә "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы салым түләүчеләр;

2) турыдан-туры пассажирлар йөртү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата метрополитеннар, шулай ук әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендәге исемлек буенча пассажирлар йөртү өчен файдаланылучы мөлкәткә карата шәһәр электр (трамвай һәм троллейбус) транспорты предприятиеләре;

3) Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары;

4) законнарда билгеләнгән тәртиптә төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге тарихи һәм мәдәни ядкарьләр дип танылучы һәм мәдәният, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат ихтыяҗлары йә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган объектларга карата оешмалар;

5) торак фонды объектларына карата оешмалар;

6) торак милекчеләре ширкәтләре, торак һәм торак-төзелеш кооперативлары;

7) халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр өлешендә су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык белән тәэмин итү, чүп-чар җыю һәм эшкәртү өчен билгеләнгән мөлкәткә карата оешмалар. Мөлкәт башка кулланучыларга хезмәт күрсәтү өчен файдаланылган очракта, оешманың салым (хисап) чорында алынган керемнәренең гомуми суммасында халыкка хезмәт күрсәтүдән алынган керем суммасына пропорциональ өлешендә мөлкәт салым түләүдән азат ителә;

8) Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмасы-резиденты балансында исәпкә алына торган мөлкәткә карата оешмалар, мөлкәтне исәпкә алу вакытыннан 10 ел дәвамында;

9) бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгын алып баруның социаль-хуҗалык бурычларын тәэмин итү максатларында кулланыла торган мөлкәткә карата гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре;

10) махсус икътисадый зоналарны булдыру һәм аларның эшчәнлеге өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә оештырылган махсус икътисадый зонаның идарә итүче компанияләре балансында исәпкә алына торган мөлкәткә карата оешмалар;

11) керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджетлардан финанслана торган казна учреждениеләре;

12) эшчәнлекләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) җирле бюджетлар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр;

13) региональ яисә муниципальара әһәмияткә һәм җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата оешмалар;

14) аэропортларның аэродром инфраструктурасы объектларына карата оешмалар;

15) нефтьнең аеруча үзле (үзлелеге 1000 һәм аннан артыграк мПа х с) чыганакларын эшкәртү (чыгару, әзерләү, яңадан эшкәртү) өчен файдаланыла торган объектларга карата оешмалар, әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендәге исемлек буенча.

2. 0,1 процент күләмендәге салым ставкасы түбәндәге мөлкәткә билгеләнә:

1) "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә буенча инвестиция эшчәнлеген тормышка ашыру өчен оешма тарафыннан яңа булдырылган, сатып алынган мөлкәткә, әгәр оешма бизнес-планда каралган шартларны үтәсә;

2) авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче һәм (яисә) балык үрчетүче оешмалар мөлкәтенә, әгәр алар җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен һәм (яисә) үрчеткән балыкны реализацияләүдән алынган керем оешма салым (хисап) чорында алган керемнәрнең гомуми суммасыннан 70 проценттан ким булмаса;

3) полиальфаолефиннар һәм алар нигезендә синтетик, ярымсинтетик мотор майлары җитештерүче оешмалар мөлкәтенә, әгәр җитештерелгән полиальфаолефиннар, синтетик һәм ярымсинтетик мотор майларын реализацияләүдән алынган керем оешма салым (хисап) чорында алган керемнәрнең гомуми суммасыннан 70 проценттан ким булмаса;

4) "Татарстан Республикасы инвестиция эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында җиңел автомобильләр җитештерүче һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектлары мөлкәтенә;

5) түләүле нигездә вакытлыча биләүгә һәм файдалануга яки вакытлыча файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән инновация проектларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә төзелгән технопарклар (индустриаль парклар), инновация-технология үзәкләре мөлкәтенә;

6) федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, физик культура һәм спорт, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата оешмалар мөлкәтенә;

7) йөк автотранспорты чараларын җитештерүчеләр мөлкәтенә.

3. 1,1 процент күләмендәге салым ставкасы түбәндәге мөлкәткә билгеләнә:

1) авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүне һәм (яисә) саклауны гамәлгә ашыручы оешмалар (акцизлы товар җитештерүчеләрдән тыш) мөлкәтенә, эшчәнлекнең күрсәтелгән төрләреннән ала торган керем оешма салым (хисап) чорында алган керемнәрнең гомуми суммасыннан 70 проценттан ким булмаса;

2) барлык оештыру-хокукый рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге фәнни-тикшеренү, конструкторлык учреждениеләре (оешмалары), тәҗрибә һәм тәҗрибә-экспериментль предприятиеләр мөлкәтенә, гомуми эш күләмендә фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм экспериментль эшләр оешма салым (хисап) чорында алган керемнәрнең гомуми суммасыннан 70 проценттан ким булмаса;

3) Россия Федерациясендә җитештерелгән һәм кимендә ЕВРО-2 экология нормаларына туры килә торган двигательләр белән җиһазландырылган автотранспорт, автотрактор һәм махсус техника (автопоездны да кертеп) җитештерүче оешмалар катнашында төзелгән лизинг бирүчеләр балансында тора торган, кимендә бер елга лизингка тапшырылган автотехникага карата, лизинг бирүчеләрнең аны лизингка тапшырудан килгән кереме оешма салым (хисап) чорында алган керемнәрнең гомуми суммасыннан 70 проценттан ким булмаса.

## 4 статья. **Салым түләү һәм салым буенча аванс түләүләрен башкару тәртибе һәм сроклары**

1. Салым һәр хисап чоры узганнан соң (аванс түләве) һәм салым чоры узганнан соң түләнә.

2. Хисап чоры өчен салым буенча аванс түләүләре хисап чорыннан соң килүче икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча башкарылырга тиеш.

3. Салым чоры узганнан соң түләнергә тиешле салым узган салым чорыннан соң килүче елның 5 апреленнән дә соңга калмыйча түләнә.

## 5 статья. **Аерым салым ташламаларының гамәлдә булу сроклары**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) 2012 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешендәге 2 – 6 пунктларын, 3 өлешен;

2) 2013 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 11 – 15 пунктларын, 2 өлешенең 7 пунктын;

3) 2019 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктын.

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында"
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## ПАССАЖИРЛАР ЙӨРТҮ ӨЧЕН ФАЙДАЛАНЫЛА ТОРГАН ҺӘМ ОЕШМАЛАР МӨЛКӘТЕНӘ САЛЫМ ТҮЛӘҮДӘН АЗАТ ИТЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ШӘҺӘР ЭЛЕКТР ТРАНСПОРТЫ (ТРАМВАЙ ҺӘМ ТРОЛЛЕЙБУС) МӨЛКӘТЕ ИСЕМЛЕГЕ

1. Трамвай вагоннары.
2. Троллейбуслар.
3. Трамвай юллары.
4. Борылыш урыннары.
5. Җиһазландырылган югары көчәнешле подстанцияләр.
6. Югары көчәнешле подстанцияләрне һәм контакт челтәрләрен тоташтыручы кабельләр.
7. Кабельле тоннель.
8. Контакт челтәре.
9. Махсус техника: йөк троллейбуслары, эретеп ябыштыру вагоннары, юу машиналары, электр каралары, вагоннар – рельс транспортерлары, автотөягечләр, автовышкалар, һәлакәт очрагында техник ярдәм күрсәтү машиналары, кар чистарткычлар.

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында"
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## НЕФТЬНЕҢ АЕРУЧА ҮЗЛЕ (ҮЗЛЕЛЕГЕ 1000 ҺӘМ АННАН АРТЫГРАК МПА Х С) ЧЫГАНАКЛАРЫН ЭШКӘРТҮ (ЧЫГАРУ, ӘЗЕРЛӘҮ, ЯҢАДАН ЭШКӘРТҮ) ӨЧЕН ФАЙДАЛАНЫЛА ТОРГАН ҺӘМ ОЕШМАЛАР МӨЛКӘТЕНӘ САЛЫМ ТҮЛӘҮДӘН АЗАТ ИТЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ МӨЛКӘТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Авыш мачта белән бораулау җайланмасы (КРЕМКО 2000 М тибындагы).
2. Скважиналарны капиталь һәм җир астында ремонтлау өчен авыш мачталы җайланма (К 54 тибындагы).
3. Горизонталь чыгару скважиналары.
4. Горизонталь пар кысып тутыру скважиналары.
5. Вертикаль пар кысып тутыру скважиналары.
6. Вертикаль чыгару скважиналары.
7. Пьезометрик вертикаль скважиналар.
8. Вертикаль контроль (бәяләү) скважиналары.
9. Катламдагы басымны тиешле хәлдә тоту системасының кысып тутыру скважиналары.
10. Эчке катламда яндыру өчен горизонталь чыгару скважиналары.
11. Вертикаль һава кысып тутыру скважиналары.
12. Металл конструкцияләреннән эстакада.
13. Кысып тутыру скважиналарының очларын җиһазлау.

14. Чыгару скважиналарының очларын җиһазлау.
15. Нефть чыгару һәм суыртып агызу өчен суыртү җайланмасы.
16. Әзер продукцияне суырта торган нефтьүткәргечләр.
17. Югары басымлы парүткәргеч.
18. Пар спутнигы белән битумүткәргеч (нефтьүткәргеч).
19. Югары басымлы һавaүткәргечләр.
20. Скважиналардан газ чыгару өчен торбаүткәргеч.
21. Ияреп чыга торган суны утильләштерү өчен торбаүткәргечләр һәм суыртү җайланмалары.
22. Пар генераторы җайланмасы.
23. Төче су үткәргече.
24. Агып төшүче суларның канализациясе.
25. Сәнәгать канализациясе.
26. Скважиналарга, төркемле үлчәү җайланмаларына, берләштерелгән суыртү станцияләренә, пар генераторы җайланмаларына һәм башкаларга үтеп керү юллары һәм мәйданчыклары.
27. Нефть әзерләү җайланмасы.
28. Нефтьне яңадан эшкәртү җайланмасы.
29. Пар эшкәртү өчен су әзерләү җайланмасы.
30. Чыгару скважиналары өчен беркетмәле торбаүткәргечләр.
31. Кысып тутыру скважиналары өчен беркетмәле торбаүткәргечләр.
32. Скважиналарны электр-химик яклау.
33. Электр белән тәэмин итү системасы (һава юлы аша электр үткәрү линиясе, трансформаторлар, кабель эстакадалары, яктырту җайланмалары һәм башкалар).
34. Контроль һәм автоматика системасы.
35. Температураны тикшереп тору буенча эчке скважина системасы.
36. Горизонталь скважиналарны бораулау өчен навигация системасы.
37. Газ белән тәэмин итү системасы (газүткәргечләр, газ бүлү пункты һәм башкалар).
38. Нефтьне исәпкә алуның коммерциячел үзәге.
39. Төркемле үлчәү җайланмалары.
40. Берләштерелгән суыртү станцияләре.
41. Пар генераторы җайланмасын төче су белән тәэмин итү өчен сәнәгать торбаүткәргечләре һәм суыртү станцияләре.
42. Компрессор җайланмалары.
43. Кайнар суны продуктив катламга агызып чыгару өчен әзерләү җайланмасы.
44. Административ бина.".

**2 статья**

2011 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Оешмалар мөлкәтенә салым турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 23 июлендәге 30-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (1 өлеш); 2009, № 11);

2) "Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында" 2009 елның 17 июнендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 11);

3) "Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2009 елның 26 ноябрендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын, 4 статьясындагы 2 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 11).

**3 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2005 елның 28 ноябрендәге 113-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 ( II өлеш); 2008, № 7 (I өлеш), ", әлеге Законның 1 статьясындагы ундүртенче һәм унтугызынчы – егерме дүртенче абзацлары 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көчләрен югалта" сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2006 елның 3 ноябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (1 өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 7 (I өлеш), ", әлеге Законның 1 статьясындагы дүртенче абзацы (2 пунктка 6 пунктча өстәү өлешендә) һәм бишенче абзацы 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көчләрен югалта" сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон 2011 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да алданрак булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 5 июле
№ 51-ТРЗ